Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге
Кара-Елга торак пунктында гражданнар җыены карары

21.11.2025 **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара-Елга торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан ,кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара Елга авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2026 елда узара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (торак пунктның эчендә Кислинка урамы юлларын вак таш белән сибү);

- урамнарны яктырту объектларын карап тору һәм аларга хезмәт күрсәтү (урамнарны яктыртуны ремонтлау);

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы _____ **С.К. Маклаков**